**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«04» март 2020 ел № 52/1

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегенә кертелгән муниципаль милекне арендага бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы 4.1 өлеше, «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегенә кертелгән муниципаль милекне арендага бирү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Боерган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе З.М.Камилянов

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советынын 2020 елның 04 мартыннан 52/1 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы « Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегенә кертелгән муниципаль милекне арендага бирү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлегенә кертелгән муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында», «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең муниципаль хокукый актлары нигезендә эшләнгән.

1.2. Исемлеккә кертелгән милек хуҗасы булып Тукай муниципаль районы « Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тора.

1.3. Исемлекне формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

1.4. Тәртип муниципаль милек исемлегенә кертелгән, өченче затларның хокукларыннан азат булган мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә файдалануга бирү өчен (алга таба – исемлек) арендага бирү процедурасын һәм мондый милекне аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирү шартларын билгели.

1.5. Тукай муниципаль районы «Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милек хуҗасы вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга вәкаләтле орган муниципаль милекне арендага бирүче булып тора.

1.6. Исемлеккә кертелгән мөлкәтнең арендачылары булып социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары торырга мөмкин, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ярдәм күрсәтелә алмый торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан тыш.

1.7. Әлеге Тәртипнең 2-3 пунктлары нигезләмәләре әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән җир кишәрлекләрен арендага бирү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагылмый.

Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән җир кишәрлекләрен арендага бирү тәртибе һәм шартлары граждан законнары һәм җир законнары нигезендә билгеләнә.

## 2. Муниципаль милекне арендага бирү

2.1. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәләрен төзү мөлкәтне арендалау шартнамәләре төзү хокукына аукцион формасындагы ачык сатулар нәтиҗәләре буенча башкарыла. Милекне арендалау шартнамәсенең срогы чыккач, мондый шартнамәне үз вазыйфаларын тиешенчә үтәгән арендачы белән яңа срокка төзү, килешүдә башкача билгеләнмәгән һәм килешүнең гамәлдә булу срогы Россия Федерациясе законнары белән чикләнмәгән булса, түбәндәге шартларны бер үк вакытта үтәгән очракта, сатулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла:

1) аренда түләве күләме объектның базар бәясен Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеген җайга салучы законнар нигезендә үткәрелә торган бәяләү нәтиҗәләре буенча таныламаларны кулланмыйча билгеләнә, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;

2) мөлкәтне арендалау шартнамәсе төзелә торган минималь срок кимендә өч ел тәшкил итәргә тиеш. Вакыт арендачының гаризасы нигезендә генә киметелергә мөмкин.

Арендага бирүче арендачыга, мөлкәтне арендалау шартнамәсен яңа срокка төзүдән баш тартырга хокуклы түгел, түбәндәге очраклардан тыш:

1) мөлкәт белән эш итүнең башка тәртибен күздә тотучы карарны билгеләнгән тәртиптә кабул итү;

2) арендачының мөлкәтне арендалау шартнамәсе белән билгеләнгән аренда түләве күләменнән бер тапкыр арткан күләмдә аренда түләве, неустойкалар (штрафлар, пенялар) буенча бурычлары булу;

3) җир кишәрлеген максатчан билгеләнеше буенча файдаланмау яки җир кишәрлеген Россия Федерациясе законнарын бозып файдалану.

2.2. Арендага бирүче сатуларны оештыру һәм үткәрү функцияләрен башкара.

Арендага бирүче килешү нигезендә сатуларны оештыру һәм үткәрү функцияләрен гамәлгә ашыру өчен юридик затны (махсуслаштырылган оешманы) җәлеп итәргә хокуклы.

2.3. Сатуларны үткәрү, сатулар үткәрү нәтиҗәләре буенча исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәләрен төзү гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2.4. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан сатуларда катнашу өчен гаризалар бирү, гаризага теркәп бирелә торган документларга таләпләр, сатуларда катнашуга кертмәүдән баш тарту өчен нигезләр аукцион турында документлар белән билгеләнә.

2.5. Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәт арендачысы үз хокукларын һәм бурычларын өченче затларга арендага бирү шартнамәсе буенча бирергә, шул исәптән субаренда шартнамәләре төзергә, мөлкәткә хокук бирергә, нәтиҗәсе булып муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәсе буенча арендаторга бирелгән мөлкәт хокукларын йөкләү булырга мөмкин булган гамәлләр кылырга хокуклы түгел.

2.6. Арендачы муниципаль мөлкәтне «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тыюларны үтәү шарты белән, максатчан билгеләнеш буенча гына файдаланырга тиеш.

## 3. Аренда хакы һәм аны кертү тәртибе

3.1. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәләре өчен муниципаль милеккә аренда түләве күләме сатулар үткәрү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

3.2. Аренда шартнамәсенең башлангыч бәясе Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турында законнары нигезендә әзерләнгән аренда түләвенең базар бәясен бәяләү турындагы хисап нигезендә билгеләнә.

3.3. Аренда түләве күләме коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә, техник хезмәт күрсәтүгә, арендага бирелгән мөлкәтне саклауга чыгымнарны һәм күрсәтелә торган мөлкәтне карап тотуга һәм эксплуатацияләүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган башка чыгымнарны, шулай ук мөлкәтне мәҗбүри иминиятләштерүгә, жир кишәрлегеннән файдаланган өчен түләүне үз эченә алмый.

3.4. Милек арендалаучы һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары булган яки социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре белән, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Боерган авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге эшчәнлегенең Россия Федерациясенең дәүләт программалары (ярдәмче программалары), Татарстан Республикасы дәүләт программалары (ярдәмче программалар), муниципаль программалар (ярдәмче программалар) белән билгеләнгән башка өстенлекле төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милекне арендалау өчен түләү буенча ташлама бирелә. Күрсәтелгән ташлама түбәндәге күләмнәрдә аренда түләвен билгеләүдән гыйбарәт:

арендаһың беренче елында – сатулар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләменең 0 проценты;

арендаһың икенче елында – сатулар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләменең 0 проценты;

арендаһың өченче елында – сатулар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләменең 25 проценты;

арендаһың дүртенче елында – сатулар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләменең 50 проценты;

арендаһың бишенче елында – сатулар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләменең 75 проценты;

3.5. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсен яңа срокка төзегәндә, арендачы тарафыннан аренда түләве 100 процент күләмендә кертелә.

3.6. Авыл хуҗалыгы кооперативлары булган яисә социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирелгән мөлкәткә карата төзелгән аренда шартнамәсен, арендачы әлеге Тәртипнен 3.4 пунктында каралган критерийларга туры килмәгән очракта, аренда шартнамәсе буенча йөкләмәләрне үтәмәүгә бәйле рәвештә, вакытыннан алда өзгәндә, муниципаль мөлкәт белән фактта файдалануның бөтен вакыты аны төзү хокукына сатулар нәтиҗәләре буенча шартнамәдә билгеләнгән аренда бәясенең 100 проценты күләмендә түләнергә тиеш.

3.7. Муниципаль милекне файдаланган өчен аренда түләве Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы « Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелә.